СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск № 195

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү сәбәпле, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кушымтага нигезләнеп үзгәрешләр кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына кертелгән үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар дәүләт теркәве узганнан һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре
Советының "27 08. 2020 ел
195 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 7 статьяның 1 өлешендәге 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелеш өчен рөхсәтләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алу, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында тәкъдимнә бирү, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән хәбәрнамәнең индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрлар буенча билгеләү һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамәне җибәрү, хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының планлаштырыла торган параметрларына туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштырырга ярамау турында хәбәр итү, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектларының яки бакча йортларының төзелеше яки үзгәртеп корганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәр итү, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән рөхсәтсез төзелгән бинаны сүтү турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру

документлары белән билгеләнгән чик параметрларга туры китерү турында карарлар, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү), максатчан билгеләнеш буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу турында карарлар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;»;

2. 7.1 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 16 пункт белән тулыландырырга:

«16) «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

3. 29 статьяда:

1) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләр, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны башкарырга тиеш.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 5.2 өлешне өстәргә:

«5.2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи заты хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциячел булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының,

күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәткә карамаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса";

3) 6 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Депутатның, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи затының вәкаләтләре "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм кешеләрнең чыгымнары белән керемнәре тәңгәл килүенә контроль турында" 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория гражданнарга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булуны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрен саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында" 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакламаганда, вазифалары вакытыннан алда туктатыла, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башкасы каралмаган булса»;

4) 8 өлештә «җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яки күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану турында" сүзләрен өстәргә;

5) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш белән тулылындырырга:

«10. Үзенең керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирмәгән депутатка, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлана торган вазифаи затына карата, әгәр мәгълүматларны бозып күрсәтү ул кадәр үк җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла ала:

1) кисәтү ясау;

2) депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасын шәһәр Советындагы вазыйфадан, җирле үзидарәнең сайланулы органыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы, шәһәр Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) шәһәр Советында, җирле үзидарәнең сайлаулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.»;

6) түбәндәге эчтәлекле 11 өлешне өстәргә:

«11. Депутатка, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи затына әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

4. 42 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәһәр башлыгы әлеге Уставның 29 статьясы 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларны башкара алмый, шулай ук хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциячел булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәткә карамаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса”;

5. 48 статьяда:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә:

- шәһәрнең генераль планы проектын һәм шәһәрнең башка шәһәр төзелеше документациясе проектларын эшли һәм шәһәр Советы раславына кертә, аларның тормышка ашырылуын тәэмин итә;

- шәһәр чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә, шәһәр территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирә

(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш);

- муниципаль милектә булган җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыруны һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

- законнарда билгеләнгән тәртиптә шәһәр территориясендәге җир кишәрлекләрен бирә һәм ала;

- шәһәр чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра;

-муниципаль урман контролен гамәлгә ашыра;

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карауны гамәлгә ашыра һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәләр бирә;

- халыкка экологик хәл турында мәгълүмат бирә, тиешле органнарга предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыра, табигатьтән файдалану турында законнарны боза торган гамәлләре турында хәбәр итә;

- шәһәр территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны үстерүне һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- шәһәр ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә, федераль закон нигезендә ясалма җир участогы булдыру турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрә;

- "Кадастр эшчәнлеге турында" 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнаша;

-индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын планлаштырыла торган төзү яисә реконструкцияләү турында күрсәтелгән хәбәрнамәгә (алга таба - планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәгә) индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның мөмкин булуы турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр җибәрә, Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең,

реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү), максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карарлар кабул итә, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимертү яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне хәл итә;»;

2) 4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак бина итеп күчерү турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннарын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны, Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип таба;»;

3) 9 пунктның өченче абзацында “7 статьяның 1 пунктындагы 8, 9, 15 һәм 19 пунктчалары белән» сүзләрен “7 статьяның 1 өлешендәге 7.1-9, 15 һәм 19 пунктлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

6. 82 статьяда:

1) 3 өлештә:

а) 1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциячел булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының,

күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр белән) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктны өстәргә:

«3.1) эшмәкәрлек белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

г) 5 пунктта «Россия Федерациясе» сүзләрен «Россия Федерациясе. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яки башка рәсми чарага бәйле рәвештә үзе алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;» сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 пунктны «, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләр, әгәр аның вазыйфаи бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек керә икән» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 5 өлешне өстәргә:

«5. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан, муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң ике ел дәвамында, хезмәт килешүе шартларында оешмада вазыйфалар биләргә һәм (яисә) әлеге оешмада федераль законнарда каралган очракларда граждан-хокукый килешү шартларында эш башкарырга хокуклы түгел, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазифаи (хезмәт) бурычларына, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгыннан башка кергән булса, ул Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган тәртиптә бирелә.».